ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2025 г.Мензелинск № 417

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Минзәлә муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат - методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында»15.04.2022 елның № 150 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.08.2025 ел № под-1344/25 боерыгы нигезендә «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында» 29.03.2022 ел №под-583/22 боерыгына үзгәрешләр кертү турында «2006 елның 22 февралендәге №15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 6 статьясындагы икенче өлешенә таянып Татарстан Республикасында Мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында», социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм Минзәлә муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 15.04.2022 елның № 150 «Педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы Минзәлә муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе составындагы мәгълүмат-методик бүлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлектә 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль берәмлекләр мәгариф бүлекләре (идарәләре) структурасындагы мәгълүмат-методика бүлекләре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфаның исеме | Айга база окладлы күләме, сумнарда | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта буын белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка "бакалавр", "магистр" яисә "дипломлы белгеч" квалификациясе бирелү белән раслана торган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 24 498,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 24 504,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы | - | - | 24 598,0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары; | | | |
| | Муниципаль берәмлекләрнең педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы). | - | - | 24 690,0. |

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисе Кондратьева Ландыш Илдусовнага һәм Минзәлә муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе Ибраһимов Ренат Мәхмүтовичка йөкләргә.

Җитәкче М.Р. Кәримов